**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 29 июне № 898/1

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын һәм күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында» 2023елның 8 февралендәге 84 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле,бакча йортын торак йорт дип ,һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакындагы ” 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ :

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 08 февралендәге 84 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә» :

1.1. 3.5 бүлегенең 3.5.7 пунктындагы 7 абзацында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Эш нәтиҗәләре буенча комиссия урыннарның һәм күпфатирлы йортларның туры килүен бәяләү турында түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- торак урынына куела торган таләпләргә һәм аның яшәү өчен яраклылыгына туры килүе турында;
- эксплуатацияләү процессында югалган торак урын характеристикаларын әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры китерү максатында бинаны капиталь ремонтланырга, реконструкцияләргә яисә яңадан планлаштырырга тиешле дип тану өчен (техник-икътисадый нигезләргә кирәк булганда) нигезләрне ачыклау турында;
- торакны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләр ачыклау турында;
- торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләр булмау турында;
- күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану өчен һәм реконструкцияләнергә тиешле нигезләрне ачыклау турында;
- күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану һәм җимерелергә тиешле нигезләрне ачыклау турында;
- күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле нигезләр булмау турында.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Баржановка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Баржанов